«Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм укырга кертү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетының 2015 елның 28 апрелендәге 176 номерлы карары (Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 24 маендагы 294 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм укырга кертү» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең Оешмага чираттан тыш укырга хокукы булган очракта, мөрәҗәгать итүчегә «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУга ташламаны раслый торган документларны, шулай ук аларның күчермәләрен тапшырырга кирәк.»;

3.3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Баланы бер оешмадан икенчесенә күчергәндә гражданнарның ташламалы категориясендәге балалар федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка законлы норматив хокукый актларда билгеләнгән ташламалардан файдалана.».

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ш.А. Алиуллов